**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Карабаш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең 23 нче подстанциясе, Октябрьнең 40 еллыгы ур. буенча теркәлгән**

**10.11.2025 ел, № 1**

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 маддәсе нигезендә, ст. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Карабаш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 18 статьясы нигезендә «2026 елда үзара салымны кертүгә ризамы Сез? " мәсьәләсе буенча 2025 елның 10 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар Җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде.Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Карабаш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2500 сум, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Карабаш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез дип яисә суд хөкеме буенча ирегеннән мәхрүм итү урыннарында тотылучы дип танылган затлардан,I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан; вакытлы хезмәттәге хәрби хезмәткәрләрдән; мобилизация буенча чакырылганнардан тыш,һәм җыелган акчаларны җирле түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (подстанция ур. 23 дән 3 дән Октябрьнең 40 еллыгы ур. 10/1 гә кадәр ВКПС күчеш өслеге белән)
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (электр үзәктән куу насосы сатып алу һәм урнаштыру)

"ӘЙЕ"  “ЮК”.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 36 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 20 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча граждannар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен граждannар Җыенының 20 катнашучысы тавыш бирде; «ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә граждannар җыены хәл итте:
1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Карабаш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Октябрьнең 40 еллыгы урамында, 23 нче Подстанция урамында теркәлгән граждannар җыенын узган дип танырга, граждannар җыены нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.
2. «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Карабаш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, суд тарафыннан хокукка сәләтсез дип танылган яки суд карары буенча ирегеннән мәхрүм итү урыннарында тотылган затлардан, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, срочный хезмәттәге хәрби хезмәткәрләрләрдән тыш, 2026 елда үзара салым кертүгә ризамы? Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлтергә:
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (подстанция ур. 23 дән 3 дән Октябрьнең 40 еллыгы ур. 10/1 гә кадәр ВКПС күчеш өслеге белән)
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (электр үзәктән куу насосы сатып алу һәм урнаштыру)-дигән карар кабул ителгән.

3. Граждannар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.Карабаш, җирлекнең рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://www.bugulma.tatar.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr:/ / pravo. tatarstan.ru).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Граждannар җыенында рәислек итүче,**

**"Карабаш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлек башлыгы**
**___________ И. И. Җәләев**

**(имза) (имзаның шифрын ачу)**